| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЧУТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2021 ел № 14

Чүти ав.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл жирлеге Советының 2015 елның 12 октябернен 9 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл жирлеге Советының 2015 елның 12 октябернен 9 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) бюджет учреждениеләренең административ һәм офис биналарын, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать объектлары урнаштыру өчен бирелгән жир кишәрлекләренә карата 0,11 %.»;

1.1. 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. Салым ташламалары.

Җир салымын түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

- гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле оешмалар (урманнар, урман парклары, парклар, скверлар, шосселар, проспектлар, урамнар, тыкрыклар, мәйданчыклар, тукталышлар, һәйкәлләр, яр буе, колонкалар, су объектлары, су башнялары, чишмәләр, коелар, артезиан скважиналары астында);

- зиратлар, үләт базлары һәм гражданнар зиратлары урнашкан җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле оешмалар һәм учреждениеләр;

- Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация узган муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары администрацияләре;

- физик затлар - янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләре һәм әлеге статусны раслый торган документны булган ирекле янгын сүндерүчеләр.».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең мәгълүмат

стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/chuteev-kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов